АГБМУ “139нчы гимназия”



# УКЫТУЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕ





**Башкарды: 2б сыйныф укучысы**
**Кәлимуллина К.И., АГБМУ “139нчы гимназия”**
**Җитәкчесе :Кәлимуллина Р.Р.**

**Казан 2019**

Нәсел агачыңны белү – һәрберебезнең изге бурычы. Барлау эшен никадәр иртәрәк башлыйсың – ул шулкадәр нәтиҗәлерәк була. Бу кирәкле дә, кызыклы да булган эш белән шөгыльләнгәндә үз нәселебез хакында әлегә түбәндәгеләрне ачыклый алдык. Алга таба шәҗәрәбез хакында күбрәк мәгълүмат тупларбыз дип ышанам.

Нәселебезнең өлкәннәре сөйләве буенча, нәселебезгә нигез салган Гәзиз бабай.Гәзиз бабайның улы Фәрхетдин, Фәрхетдин улы Сәйфулла, Сәйфулла улы Шәрипҗан(140 яшенә кадәр яшәгән, шуңа күрә безнең нәселне Шәреп нәселе дип атыйлар), Шәрипҗан бабамның улы Галиулла.Без (әбиемнең кыз фамилиясе) фамилиябез итеп аның исемен йөртәбез.Галиулла улы Хәкимулла, Хәкимуллаулы Гыйльметдин- минем әбиемнең әтисе була. Хәкимулла бабай авылыбыз тарихында билгеле шәхес. Халык аны бик яраткан, аның янына киңәш сорап килгән. Ул үз авылында мулла булган (Хәким+мулла=Хәкимулла исеме). Минем әби сөйләвемчә Шәрипҗан бабайның әнисе мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәчесе, тарихчысы, дин әһеле, педагог, археолог, этнограф, көнчыгыш халыклар белгече Шиһабетдин Мәрҗани нәселенә килеп тоташа.Моның турында әле күп эзләнүләр алып барырга кирәк. Шиһабетдин Мәрҗани 1818 елның 16 гыйнварында Казан өязе (хәзерге Әтнә районы) Ябынчы авылында руханилар гаиләсендә дөньяга килә. Аның бабасы Габделкотдус Мәрҗани авылы кешесе була. Шиһабетдин соңыннан бу авыл исемен үзенә псевдоним итеп ала.

“ Мәрҗән” дигән атамының килеп чыгышын әбием болай дип аңлатты. Бу авыл Казаннан 60 км ераклыктатаулы, җиләкле, матур күлле,өч куаклык арасында ( бер куаклык -эчә торган,тигез урын,монда бәйрәмнәр үткәрелгән, икенче таудагы куаклык,өченчесе Әптеки куаклыгы) урнашкан.

XVIII азагында бер байхатыны белән күл янына туктап, ял итеп алган арада, аның хатанының күлдә юынганда кыйммәтле, кадерле мәрҗәнеөзелә һәм суга чәчелә.

Шул урыннан ерак булмаган урында бай йорт салып яши башлый.Гади халык өчен бу зур вакыйга була һәм бу урында урнашкан авылга Мәрҗән исеме бирелә.

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда нур... – ди.

Г. Тукайның "Пар ат"

Бу Мәрҗән дигән авылда әбиемнең әтисе Гыйльметдин бабай Хәкумулла гаиләсендә 1925 елда дөньга килә.




Табигате белән зирәк һәм белемгә омтылышлы булуы, элеккеге заманда яшәгән тарихи шәхесләрнең биографияләре, төрле вакыйгалар белән танышу аның дөньяга карашын киңәйтүдә һәм шәһес булып җитешүендә зур роль уйныйлар.
Сугышка хәтле яшь булуына да карамастан, ул 7нче сыйныфны тәмамлагач механизаторлар мәктәбенә киткән, туган авылында автомеханик булып эшләгән.

Ләкин тыныч тормышта яшәү бәхете озакка бармый, 1943 нче елда ук унсигез яшьлек егет сугышка китә. Гыйльметдин бабам дәһшәтле сугышның җиңү көннәренә чаклы авыр юллар кичкән. Ул һава-десант дивизиясендә сапер-минер, минометчик, разведчик булып немецларны Польша, Чехословакия, Хорватия җирләреннән куа. Немец пулясы астына чак кына эләкми калган көннәре шактый. Ләкин танкка каршы ташлаган минаның бер өлеше бабамның башына эләгә һәм ул 7 ай госпитальдә дәвалана.Тазара башлагач яңадан сугышка керә. Ул бик авыр бәрелешләрдә катнашкан. Җиңү таңын ул Берлинда каршы алган. Нинди генә орден-медальләре юк аның. «СлаваII степени” «Слава III степени”, «Орден Жукова», «За отвагу» медальләре.








Сугыш тәмамланса да, ул туган җиренә 2 елдан соң гына 1947 елның февралендә әйләнеп кайта, чөнки сугыштан соң илне тагын да ныграк сакларга кирәк була.Туган авылында калмыйча ул абыйсы Әхмәтмөнир мулла белән Әтнәгә күчеп китә. Безнең бабайның нәселе Мәрҗәни нәселеннән булгангадыр микән ул укытучы булып эшләп йөргән Разыя белән таныша.Алар матур гаилә корып җибәрәләр. Аларның 7 балалары туа, ләкин 3генә хәзергә исән-сау.

Минем әбиемнең әнисе, Гәлиуллина Разыя Юныс кызы, 1922 нче елда Күшәр авылында колхозчы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килгән. Әтисе һәм әнисе күп вакытларын эштә уздыралар. Берсе артыннан берсе балалар туа. Ашарга ризык аз, гаилә зур, барысы да ашарга сорый, шунлыктан әби “бәхет эзләргә” Мари Элның Бәрәңге районына укырга, укытучы булырга чыгып китә. Разыя әби укып бетереп, Кече Әтнәдә укытучы булып эшли башлый, гаиләсенә ярдәм итә. Аннан соң Әтнә авылына күчеп китә. Яшь белгеч сугыш елларында политрук булып тырышып эшли. Сугыштан соң Әтнәгә хезмәт итеп кайткан Гыйльметдин бабай белән таныша.Гыйльметдин бабам сугышта гына түгел, тыныч көннәрдә дә сокланырлык шәхес булган ул. Дәү әти кул эшләренә дә бик оста: тәрәзәләр куя, тимер, агачтан төрле йорт җиһазларын да үзе ясый иде. Дәү әти авылда бакчачы һәм умартачы буларак та дан тотты. Күршеләрне,туганнарны һәрчак бал һәм алмалар белән сыйлады. Безне - үзенең балаларын һәм оныкларын да юмарт, итагатьле итеп күрергә теләде.



Мәрҗани нәселеннән булгангамы Гыйльметдин бабай шигырьләр дә язгалаган. Бу фикерне исбат итү өчен дәлил итеп бу үзенең нәселе турында язылган шигырен китерәм.
Разыя әби Әтнә мәктәбендә укыткан чорда башлангыч татар мәктәпләре өчен татар теле дәреслекләре (Р.Г. Вәлитова, С.Г. Вагыйзов «Язарга өйрәтү дәфтәре», “Татар теле») апробация үтә. Шул чорны әби бик сагынып искә ала иде, чөнки дәресләр укытып чыгуга дәреслек авторлары белән бергәләп һәр дәресне аназлап бара торган булганнар. Әби шул елларны өйгә бик соң гына кайтып керә торган булган. Өйдә балалар, тормыш иптәше 5 көн күрше авылда (Ыртыйста)эшли, ялга гына кайта торган булган. Балалар әнисенең эше бик җаваплы икәнен аңлап әниләренә тормышны алып барырга булышканнар. Разыя әбинең һөнәрен дәвам итеп ике кызының (Флера белән Фираяның) да кызлары укытучы булып хәзерге көндә берсе Гөлшат Нәүфәловна Мари Элда, берсе Резедә Рафкатовна Казан мәктәбендәэшли.Олы малаеның кызы Гүзәл Фердинантовна КФУда юридик факультетында укыта.

Киләчәктә нәселебез шәҗәрәсен тирәннән өйрәнүне үземнең бурычым дип саныйм, чөнки шәҗәрәләр безгә якын кешеләребез, үз нәселебез аша халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли. Шәҗәрә агачын, буыннар тезмәсен, гаилә тарихын төгәл эшләү өчен төрле мәгълүмат туплау шактый вакыт сорый, тапкан материалларны җентекләп тикшерүне таләп итә.

«Һәр кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш, —дигәннәр борынгылар. — Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, үз халкының үткәнен яхшы белә».
Кеше җирдә ни өчен яши? Үзенең кыска гына гомере эчендә ул барысына да өлгерергә, барын да танырга, белергә, үзе эшләп калырга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне җиңеп чыгарга һәм, иң мөһиме, үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш.

| Газиз | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Фахрутдин | | | | | | | | | | | | | | | |
| Сайфулла | | | | | | | | | | | | | | | |
| Шарипжан(прожил 140лет) | | | | | | | | | | | | | | | |
| Галиулла | | | | | | Кабир(скрипач) | | | | | | | | | |
| **Галиуллин Хакимулла Галиуллович мой прапрадед** | | Галиуллин Даулат Галиуллович брат прапрадеда | | Галиуллина Хайерниса Галиулловна сестренкапрапрадеда | | Кабиров Юнус Кабирович **мой прапрадед** | | Кабиров Зиннур Кабирович брат прадеда | Ахметханов Ахметхан **прапрадед** | | Кадыров Абдулла, **прапрадед** Кадырова Махруй **прапрабабушка** | | | | |
| Галиуллин Гильмутдин Хакимович (**Мой прадед**)1925 | Галиуллин Нуриахмет Хакимович братишка прадедушки | Галиуллин Ахметмунир Хакимович братишка прадедушки | Галиуллина Тахира Хакимовна Сестренка прадедушки | Галиуллин Нурмухаммет Хакимович братишка прадедушки | Галиуллин Газиз Хакимович братишка прадедушки | Галиуллина-Кабирова Разия Юнусовна **моя прабабушка**1923 | Кабиров Идрисбратишка прабабушки (дети: Раис, Раиса, Рамля) | Кабиров Ильдус Юнусович братишка прабабушки (дети: Галия, Ильгиз) | Ахметханов Фазылжан Ахметханович **(мой прадед)** | Ахметханова Өмегелсем Сестренка прадедушки | Кадырова Разия Абдулловна (дети: Салихова Фатыйма,Фирдаус, ЛатыповаФаузия) Сестра прабабушки | Кадырова Амина Абдулловна **Моя прабабушка** | Кадырова – Латыпова Фатыйма Абдулловна (дети:Рами, Раим Сестренка прабабушки | Кадыров Гомәр Абдулович | Кадырова - Ахтямова Мәдинә (дети: Наиля, Ахтям) Сестренка прабабушки |
| Ахметханова-Галиуллина Фирая Гильмутдиновна (**моябабушка**) 1949 | | | Фатхуллина - Хузиева Флера Нурмиевна **сестра бабушки 1941** ( Фатхуллины Фарит Науфалович, Фатхуллин Фаргат(сын, дочь) Науфалович, Фатхуллин Шаукат Науфалович(2дочери), ФатхуллинаГульшат Науфаловна(Гузель) ) | | Галиуллин Фирдинат Гильмутдинович 1951**братишка бабушки** (его дочь Галиуллина Гузель Фирдинатовна ( внучка Алина ), Галиуллин Марат Фирдинатович) | | Галиуллин Ринат Гильмутдинович 1954 **братишка бабушки** (Дочери Галиуллина Энже Ринатовна(внук Булат),Галиуллина Эльза Ринатовна(сын) | | Ахметханов Борис Фазылович **брат дедушки** (сыновья Ильсур(дети:дочь,Эльза), Рамиль (дети:Руслан, сын)Алмаз(дочь)) | | Ахметханов Ильдус Фазылович 1940 **брат дедушки** (сыновья Ильгизар и Ильяр, дочери Ильсия (Илюза, Фируза) и Айгуль (Зиля Замира) | Ахметханов Рафкат Фазылович 1945 (дочь Резеда, сыновья Айдар, Айрат)**мой дедушка** | Ахметханов Гарибжан Фазылович 1947-1969 (сын Ахметханов Альберт Гарибжанович )**братишка дедушки** | Ахметханов Гумер Фазылович 1955 (дочь Ахметханова Алсу Гумеровна)**братишка дедушки** | |
| Калимуллина(Ахметханова)Резеда | | | | | Ахметханов Айдар Рафкатович1973 | | | | | Ахметханов Айрат Рафкатович 1983 | | | | | |

Хәкимулла(Мулла)



Әхмәтмөнир(мулла)



Галиуллинар гаиләсе (Гыйльметдин белән Разыя)



## Разыя Юныс кызы(башлангыч сыйныф укытучысы)





***Оныклары(укытучылар)***

Гөлшат



Гүзәл



Резедә



Кеше җирдә ни өчен яши? Үзенең кыска гына гомере эчендә ул барысына да өлгерергә, барын да танырга, белергә, үзе эшләп калырга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне жиңеп чыгарга һәм, иң мөһиме, үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш.








